ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Александровка авыл җирлегенең Яхшы-Каран торак пунктында
2022 елда үзара салым кертү турында

18 ноябрь 2021 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елнын 06 октябрендәгы № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Александровка авыл җирлегенең Яхшы-Каран авылында гражданнар җыены

КАРАР БИРДЕ:

1. 2022 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Александровка авыл җирлеге Яхшы-Каран авылы территориясендә I группа инвалидлардан, ялгыз өлкән кешеләрдән (80 яшькә җиткән ) һәм көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 250 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1) Яхшы-Каран авылы Идрисов урамына вак таш түшәү;

2) Яхшы - Каран авылынды урам фонарьларын сатып алу һәм ;

3) Өлкәннәр көненә, инвалидлар көненә бүләкләр алу;

4) «Сабантуй» һәм «Яңа ел» бәйрәмнәрендә призлар һәм бүләкләр сатып алу;

3. Әлеге карарны Александровка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында ( http:// sarmanovo. tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Александровка авыл җирлеге башлыгы
гражданнар җыенында рәислек итүче А. Р. Гафиятуллин